# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ №6

2019 елның 12 декабреннән

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Коркачык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында", 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 22 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта, 2019 елның 3 декабрендә 16 сәгать 00 минутта, 14 декабрендә 16 сәгать 00 минутта уздырылган "Сез 2020 елда Иске-Казан авыл җирлеге Коркачык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

а) Коркачык авылы эчендәге юлларны чокырлар ремонтлау;

б) Коркачык авылында яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру ;

в) Коркачык авылы һәйкәлен ремонтлау; «РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 576 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 296 кеше, бу 51,39 % ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 293 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Коркачык торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

"Сез 2020 елда Иске-Казан авыл җирлеге Коркачык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

а) Коркачык авылы эчендәге юлларны чокырлар ремонтлау;

б) Коркачык авылында яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру ;

в) Коркачык авылы һәйкәлен ремонтлау;

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске-Казан авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Закирова